ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 352 «17» 06 2022 ел

2022 елның II кварталына социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә кую турында карар кабул итү өчен мөлкәтнең иң чик күрсәткечләрен һәм бәясен раслау хакында.

Торак кодексының 49, 51 статьялары, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү методикасы, югарыда аталган законга кушымтада бәян ителгәннәрдән чыгып, 2022 елның II кварталына Спас муниципаль районы торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 1 октябрендәге 630 номерлы карары нигезендә, Спас муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 2 кварталына социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә кую турында карар кабул итү өчен түбәндәге максималь чик күрсәткечләрне расларга:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм торак урыны базар хакының исәп-хисап күрсәткеченә гаиләнең һәр әгъзасына 386734,50 сум күләмендә социаль наем буенча торак урыны бирү нормасы буенча салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме.

1.2. һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем кыйммәте бусагасы 9023,80 сум күләмендә.

2. Спас муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә, Спас муниципаль районы Болгар шәһәр башкарма комитетына торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдаланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында урнаштырырга (//http:pravo.tatarstan.ru).

4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе — В.А. Осокин